КАНАТЛЫ КИЛӘЧӘК

Казанда авиатөзелеш тармагында импорт алмаштыру турында сөйләштеләр

> 2

АНА КАПИТАЛЫ

Татарстанда гаиләләрнең 80 проценты бу акчаны торак шартларын яхшырту өчен куллана

> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ

«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 113 (28886) | Шимбә | 6 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

РУЛЬ ТҮГЕЛ УЕНЧЫК

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Хәерле юл!

Чәчләр үрә торырлык статистика: 2022 ел башыннан Россия юлларында машина йөртүче... балалар (!) катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны 27,9 процентка арткан. Алты ай эчендә шундый 376 очрак теркәлгән. Зыян күрүчеләр саны 369 кешегә җиткән. Былтыргы саннардан 32,3 процентка артыграк монысы.

Штраф кына коткармас

Әлбәттә, юл-транспорт һәлакәтләрендә нарасыйларның зыян күрүе – күңелсез күренеш. Тик балигъ булмаганнарның бәла-каза сәбәпчесе булуы тагын да аянычлырак бит. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен аларга һәм аларның ата-аналарына да җәза бар. Аны тагын да катгыйландырырга җыеналар. Чөнки Россия Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге фәнни үзәге хисабында китерелгән саннар хафага сала.

Россия административ хокук бозулар кодексының 12.7 маддәсе 3 өлешендә әйтелгәнчә, балаларын рульгә утырткан ата-аналарга 30 мең сум күләмдә штраф яный. Шунысы да бар: кабат тәртип бозу очрагы теркәлсә, өстәмә рәвештә җавапка тарту каралмаган. Машинаны да тартып алмыйлар, кисәтү дә ясамыйлар.

Дәүләт Думасында штраф биреп кенә бәладән котылып булмый дип саныйлар. Шуны исәптә тотып, кагыйдә бозучыларны мәҗбүри эшләргә җәлеп итәргә теләләр. Бу тәкъдимне махсус комитет утырышында уртага салып сөйләшергә җыеналар.

Дума депутаты Ярослав Нилов фикеренчә, 30 мең сум штраф та аз акча түгел. Әмма кешесенә күрә бу сан гына кагыйдә бозудан туктатмаска да мөмкин. Ягъни, билгеле, халык арасында азмы-күпме танылу алган, акчасы булган кешегә бу сумма – тиеннәр генә.

– Административ җаваплылык белән генә эшне хәл итеп булмый. Тәэсир итүнең башка юлын – мәҗбүри эшләрне кулланырга кирәк. Кешегә җәза буларак урам себерергә, зиратлар чистартырга һәм башка нәрсәләр эшләргә туры килсә, әхлакый-психологик басым да ясалачак, – дигән фикердә депутат.

vk.com

Сүз дә юк, өстәмә чаралар күрү – мәсьәләнең бер ягы гына әле. Ата-ана һәм балалар белән даими аңлату эшләре алып бару турында да онытмаска кирәк.

Уеннан уймак ясамасыннар

Андый хәлләр ил күләмендә еш очрап тора. Әти-әниләр балаларын «тимер ат»ка яшьтән үк өйрәнсен дипме, машинаны уенчык дип белепме, балаларын рульгә утыртудан курыкмый. Күпләр «хайп» дигән замана сүзе артыннан да куа. Әмма соңрак балага да, ата-анага да кыен ашарга туры килмәгәе.

Александра Коршунова дигән блогерның интернет киңлекләрендә таралган видеосы да күпләрне гаҗәпләндергәндер. Аның бер яшьлек улы, әнисенең итәгенә утырып, шәһәр урамнарыннан җилдерде.

Шуңа охшаш очрак бизнесмен Антон Гусев белән дә кабатлана. Рульгә ул сигез яшьлек улын утыртып, аның машина йөртүен социаль челтәрләргә урнаштыра. «Балачактан өйрәнсен» дип өстәргә дә онытмый куркусыз әти.

– Һәр ата-ана, балалар юл-транспорт һәлакәтенә очраклы рәвештә эләгә, дип уйлый. Алар барысын да гаепләргә мөмкин, тик үзләрен генә түгел. Балагызның руль артында баруына бары тик сез гаепле булачаксыз, чөнки сез аның өчен җаваплы, – ди Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча ЮХИДИ юл-патруль хезмәте полкы командиры Михаил Савин.

Ерак юлларга йөрүче татар «дальнобое» Назыйм Галимовның бу җәһәттән үз фикере.

– Балаларны рульгә утыртып йөрүчеләргә карата мөнәсәбәтем тискәре. Тәкъдим ителгән җәза да йомшак әле ул. Рульгә бала белән утыруны машинага хәмер кулланып утыруга тиңләр идем. Нигәме? Бердән, бала белән руль артына утыру, иң элек, аны бик зур куркыныч астына куя. Утыргыч белән руль арасы тар. Машинаны идарә итүче, бала да сыйсын дип, урындыгын артка этәчәк. Кагыйдәләрдә язылган бит: машинага утыргач та, йөртүче утыргычны үзенә уңайлы итеп көйләргә тиеш. Шул очракта гына юлда йөрү хәвефсез була. Аннан, бала алда булганда, «обзор» каплана. Борын төбендә – бала башы. Ул да бит тик утырмый. Җәяүле чыгамы, йорт хайванымы, велосипедчымы, техникамы – аны күрергә кирәк бит. Шул вакытта машинаны кисәк туктатырга туры килә. Физика законы буенча, тормозга баскач, без алга этеләбез. Бала да ике арада калып, кысылып, берәр җирен имгәтергә мөмкин. Ни кызганыч, юл һәлакәтләре гел булып тора. Үзең генә йөргән очракта да юлда куркыныч әле. Син тәртипле генә йөрсәң дә, сиңа килеп бәрелүләре бар! Гаепсездән гаепле булып куярга да мөмкин, – ди тәҗрибәле юлчы. – Баланы рульгә утыртып, видеога төшереп куюны да аңламыйм. Мин булдырам, син – юк, дип кылану кебек кабул итәм моны. Мактану, шапырыну. Социаль челтәрләрдә шуны куеп, «лайк» җыю, «хайп» артыннан куу – менә шуның өчен эшләнгән нәрсә бу. Үз мәнфәгатеңдә балаларны куллану! Хәтта балаларын да җәлләмиләр. Шул дәрәҗәдә куркыныч нәрсә бит бу! Бала сорый дип инде... Үз яшьләре җиткәч, утырырлар. Машина хәрәкәт итмәгән очракта да балаларны анда калдырырга ярамый дип саныйм. Үземнең дә ике малай. Утыртканым юк. Алар сорамый да, ни икәнен беләләр. Уйнар өчен рульдән кала да уенчык мулдан.

Баланың курчак түгеллеген онытып җибәрәләр. Назыйм Галимов әйтүенчә, ата-ана менә шуны истә тотсын иде. «Бала – тере кеше. Рульне тота, машинаның башка детальләренә үрелә, рульнең ярыкларына кулын тыга. Тиктомалга гына балалар өчен махсус утыргычлар уйлап тапмаганнар бит инде. Куркынычсызлык каешлары да юкка түгел», – ди ул.

Бик көчле Президент

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов июль ае нәтиҗәләре буенча Россия төбәкләре җитәкчеләренең сәяси йогынтысы рейтингында беренче бишлеккә кергән. Исемлекне Сәяси һәм икътисади коммуникацияләр агентлыгы әзерләгән. Президент «Бик көчле йогынты» категориясендә дүртенче урынга чыккан. Аның уртача баллы 7,19ны тәшкил итә. Рөстәм Миңнехановның июнь рейтингында алтынчы урын алуын искә төшерик.

Июль ае рейтингында җитәкчеләрнең зур федераль чаралар үткәрергә әзерләнү, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру, табигать афәтләренең аянычлы нәтиҗәләрен бетерү кебек эшләре исәпкә алынган.

Продукция җитәрлек

Быел Татарстанда авыл хуҗалыгы продукциясе җитәрлек күләмдә булачак. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Наил Залаков: «Язның – суык, җәйнең бик эссе килүенә карамастан, авыл хезмәтчәннәренең чәчү эшләренә әйбәт әзерләнүләре нәтиҗәсендә продукциягә кытлык көтелми», – дип белдерде. Республика кайбер азык-төлек буенча үзен 100 проценттан күбрәккә тәэмин итә. Әмма беришен башка төбәкләрдән дә кертергә туры киләчәк.

Министр урынбасары сүзләренә караганда, үсемлек мае белән – 600 процентка, шикәр комы белән 300 процентка тәэмин ителгәнбез. Бу – 20 ел дәвамында алып барылучы планлы эш нәтиҗәсе. Дөге һәм җиләк-җимештән кала, социаль әһәмиятле продукцияне үзебезгә тулысынча җитәрлек күләмдә җитештерәбез.

Шулай ук Наил Залаков азык-төлеккә бәянең кискен артуы көтелмәвен дә белдерде. Шуның белән беррәттән, сезонга бәйле рәвештә, кайбер азык-төлеккә бәя бераз үзгәрергә мөмкин. «Хәзер җәй, шуңа күрә яшелчәгә бәя төшә, тавык ите һәм йомырка бәясе кими, әмма сезонга бәйле рәвештә алар күтәрелергә дә мөмкин», – диде ул.

80 кеше һәлак булган

Ел башыннан бирле Татарстанда 3 меңгә якын янгын очрагы теркәлгән. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе хәбәр иткәнчә, 80 кеше, шул исәптән өч бала һәлак булган. Моннан тыш янгыннарда 115 кеше зыян күргән, 218ен коткарып калуга ирешелгән. Алдагы көнне Чаллыдагы күпфатирлы йортта янгын чыккан. Фаҗигадә ике баланың (2017 һәм 2019 елгы) гомере өзелгән. Әлеге очрак буенча җинаять эше кузгатылган.

Нәтиҗә

Иң көчле корал – сүз

Казанның «Пирамида» концертлар залында 25 нче тапкыр уздырылучы «Бәллүр каләм» бәйгесендә җиңүчеләрне тәбрикләделәр. Җиңүчеләр арасында «Ватаным Татарстан» газетасы да бар. Ә гран-при – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән автомобиль КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире, күп кенә журналистлар тәрбияләгән остазыбыз Васил Гарифуллинга бирелде.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев 2021 елның журналистика тармагы өчен уңышлы булганын әйтте. «Бүген без ел нәтиҗәләрен чыгарабыз. Иң талантлы, иң тырыш журналистларны бүләклибез. Бик күп уңышларыбыз, күрсәтерлек эшләр җитәрлек. Эшләрен күреп бүләкләрлек кешеләребез бар», – диде ул.

Бу, чынлап та, шулай. Сәхнәгә журналистларны котларга чыгучылар барысы да җылы сүзләр генә әйтте. Татарстан Журналистлар берлеге рәисе, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов та каләм ияләренә аерым рәхмәтен белдерде.

– Әле күптән түгел ялда булдым. Сәяхәт вакытында күп кенә урыннарда йөрергә туры килде. Шунда гел бер төрле рәсемгә тап булдым. Ярлы кешене фәрештәләр өскә өстери, шайтаннар – аска. Журналистикада да шулай. Берәүләр матурлык, яктылык күреп, кешеләргә ярдәм итеп яза, икенчеләргә хайп кирәк. Ә бу бәйрәмгә яктылык күрүчеләр җыелган, – диде ул. – Кайчандыр остазым Флорид Әгъзамов: «Журналистикада иң мөһиме – гуманлылык», – дип әйткән иде. Башкача мөмкин дә түгел. Кешеләргә булышу, аларны ярату кирәк. Булдыра алганча без башкаларга ярдәм итсәк иде.

Татарстанның Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева республика җитәкчелеге исеменнән тәбрикләп кенә калмады, теләкләрен дә җиткерде.

– Хезмәтегез өчен зур рәхмәт, – дип башлады ул сүзен. – Сезнең кулда Җир йөзендәге иң көчле корал. Ул – сүз. Сүз кешегә канатлар куярга да, кешелек тарихын юкка чыгарырга да мөмкин. Сез безнең республика, ил тарихын язасыз. Безнең республикабыз һәркайсыгыз өчен көч алу урыны булсын иде. Бергә эшләвебез, кешеләрне борчыган сорауларны күтәрүегез, сәламәтлек, социаль яклау темаларына сак кагылуыгыз өчен, сабыйлар, әти-әниләр турында язуыгыз өчен рәхмәт.

«Татар-информ»

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Тимур КАДЫЙРОВ, Татарстанның яшьләр ассамблеясы рәисе:

Татарстан милли сәясәт өлкәсендә үрнәк булып тора ала. Ни өчен бездә үтүче һәр бәйрәмгә башка милләт вәкилләре дә килә? Чөнки алар зур итеп уздырыла. Бу чаралар матбугатта, социаль челтәрләрдә тарала. Шунлыктан милли бәйрәмнәр туристларны җәлеп итә дә инде.

(«Территория смыслов» форумыннан)

РОССИЯДӘ – СӘЯХӘТ ИТҮ

Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү фонды (ФОМ) уздырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, ил халкының 69 проценты чит илдә булганы юк. 17 процентының Россия төбәкләрендә сәяхәт иткәне бар.

Сочи һәм Краснодар крае курортлары	>> 33%
Мәскәү, Кырым, Санкт-Петербург	>> 19%
Казан, Самара, Саратов, Түбән Новгород, Волгоград, Әстерхан	>> 14%

Эссе җәй дәвам итә

Киләсе атнада да эссе булачак. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, 8–9 августта көндез термометрның терекөмеш баганасы +30 күрсәткеченнән югарырак торачак. Явым-төшем ихтималы аз.

Якшәмбе – 7 августта көндез +28...+33, төнлә +12...+17 градус җылы. Атмосфера басымы югары булу сәбәпле, яңгырлар көтелми. Исегезгә төшерәбез: Татарстанда эссе, коры һава торышы хакимлек итү сәбәпле, урманнарда янгын куркынычын кисәтү режимы озайтылды. Киләсе атнага республика урманнарында югары дәрәҗәдә – IV класслы янгын куркынычы билгеләнде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тау куышына керәбезме?

Бу атнада, ихтимал, XVI гасырда ук үлгән Николай Коперник каберендә чираттагы тапкыр әйләнеп яткандыр. Сишәмбе көнне җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүче рәсми оешма – ВЦИОМ илдәге халыкның гомуми гыйлем дәрәҗәсен белергә теләп үткәрелгән сораштыруларның сенсацион дип бәяләрлек нәтиҗәсен игълан итте. Аның буенча, россиялеләрнең өчтән бере (35 процент!) Җир Кояш тирәли түгел, ә Кояш Җир тирәли әйләнеп йөри дип саный икән. Менә шулай. XXI гасырда, фән-техника, югары технологияләр заманында, югары белемлеләр саны соңгы ике-өч дистә елда геометрик прогрессиядә артып торганда һәр өч кешенең берсе шыр надан дигән сүз бит бу.

Кояш белән Җирдән кала сораштыруларда әле тагын «Радиация белән зарарланган сөтне кайнатсаң, ул чистарамы?», «Борынгы кешеләр динозаврлар белән бер чорда гомер иткәнме?» ише сөальләр дә булган. Соңгы сорауга һәр биш кешенең берсе, күзен дә йоммыйча, «әйе» дип җавап биргән. ВЦИОМ отчетында гавамдагы эрудиция, гыйлемнең «үсеш»ен билгеләүче тагын бер сан бар – соңгы 15 ел эчендә Кояшны Җир тирәли әйләндереп, дөньяны Урта гасырлардагыча күрүчеләр 7 процентка арткан (2007 елдагы сораштыруларда андый «акыллылар» 28 процентны тәшкил иткән булган). Урта гасырлар дигәннән, Коперник кына түгел, аның тәгълиматын актив тараткан итальян монахы Джордано Бруно да, монахны утта яндырырга хөкем иткән һәм яндырган чиркәү суды – инквизиция вәкилләре дә әйләнгәндер кабердә. Соңгылар: «Шөкер, безнең чор, безнең инанулар кайта», – дип, чиксез шатлангандыр да әле.

Һәр дәвернең үз Урта гасырлары була, дип юкка әйтмиләрдер, Россия генә түгел, куллану җәмгыятен иярләгән кешелек тә акрынлап шуңа таба бара кебек. Әле ул чорда гына туктап кала алсак ярый да. Бит, әйтүләренә караганда, артка чигү, ягъни инволюция, аңа кереп китсәң икән, эволюциягә караганда күпкә тизрәк бара. Кызып китсәк, бүгенге «homo sapiens» (зиһенле кеше) иртәгәгә «homo erectus» (ике аягына баскан кыргый кеше), тагын бераздан, агач башына ук менгән тәкъдирдә «homo habilis»ка (маймыл-кеше) ук әверелергә мөмкин.

Деградация сүзе татарча затсызлану, түбәнгә төшүне аңлата. Ничек, нинди сәбәпләр безне ул халәткә илтә соң? «Яхшылану»ның алшартлары билгеле кебек: акча, мал, уңайлыклар, күңел ачу артыннан ярыша-ярыша чапканда, эрудиция, гыйлем кеше затына ниемә? Ул дивидендлар китерми бит. Бәндәне материаль кирәклек йөрткәндә, үзең яшәгән дөньяны танып белергә омтылуның хаҗәте шуның чаклы гына. Файда, әҗер юк чөнки. Затлы машинада йөрүче танышым әле һаман Швеция белән Швейцарияне аермый. Бүгенге обыватель нинди дә булса романтикадан даерак. Ул – даими исәп-хисап белән яшәгән прагматик. Без үскәндә космонавт, очучы булырга хыяллана идек. Тик «Космонавт күпме ала икән?» дигән сорауның башыбызга да килгәне булмады. Бүген исә беренче шул сорау куела. Гомумән, 30–40 ел элек кенә без сөйләшкән өлкәдә вазгыять башка иде. Совет чорының икенче яртысында гыйлем, интеллект дигән категорияләр, бүгенгечә әйтсәк, трендта булып, укуга, китапка мәхәббәт хәтта ки культ, табыну рәвешенә керә башлаган иде. Акча, мал-мөлкәт, аңа ашкыну алдан йөрмәде чөнки.

Бүген кешелекнең «продвинутый» өлеше үзен уңайлыклар белән урап алды. Бу – һәркемнең эчендә посып яткан затсыз сыйфат – ялкаулыкның тышка чыгуы. Чишмәгә суга йөрисе юк, су краннан ага. Утын кисәсе, ярасы да юк – үзәкләштерелгән җылыту системасы өйне май итеп тора. Ит ашау максатыннан печән чабасы, мал асрыйсы да түгел – итне дә, май белән сөтне дә сатып кына аласы. Болар барысы да бүген табигый, шулай булырга тиеш, дөрес тоела. Бәлки дөрестер дә. Тик мондый «эшсезлек», әзергә-бәзерлекнең кире ягы шактый хәтәр, дияр идем. Артыкка киткән комфорт, рәхәтлек кешене азындыра. Көрәшкә, бәндәне тонуста тотучы киеренкелеккә урын калдырмый. Мотивация югала. Йомшау, канәгатьлектә перспектива аз. Эволюция көрәштә калганнарны, тонуста торганнарны ярата. Инволюциянең беренче чаткыларында: түбәнгә юнәлү, наданлану, деградациянең нигезендә шушы хәл дә ятмый микән? Биредә дә куллану җәмгыяте алып килгән бәлаләргә юлыгабыз.

Затсызлану, куллану җәмгыяте дигәндә, хәзерге яшәешнең тагын бер ягына күз саласы килә. «Ачның күзе – икмәктә, тукның күзе – хикмәттә» дигән әйтем дә бар бит әле. Кеше заты күңел ачарга, тамашага артык маһир бүген. Күңел ачу ул кырын ятып телевизорга багу, футбол фанаты булу гына түгел, ул – наркомания, эчкечелек тә. Тамашага мөкиббәнлек шул дәрәҗәгә җитте: бүгенге дөнья культурасының үзәк фигурасы, миллионнарның кумирлары дигәндә, актерны һәм җырчыны атау дөрес. Космонавт, галим, ул Нобель премиясе лауреаты булганда да гавамны кызыксындырмый. Артистларны исә беләләр, тормышын, һәр хәрәкәтен күзәтәләр, алар булырга, алар кебек кыланырга, хәтта аларча киенергә тырышалар. Телевизорда, кайчан карама, алар катнашында эшләнгән реклама, һәрберсенең – үз фанатлары. Фикер иясе, язучы, галим кебек тирәндә казынырга, нәтиҗә, анализга хирыс затлар түгел, нәкъ менә актерлар дөнья кендеге бүген. Гәрчә актер да, җырчы да әзер текстны, көйне трансляцияләүче һәм кемдер булып кыланучы гына булса да. Актер ул – күзгә күренмәс җепләр кулын, аякларын, телен тарткалап торган курчак. Антик чорларда палач һәм актер иң хурлыклы һөнәр ияләре саналган. Чөнки тормышта үзең булу, үзеңне табу беренче урында торган. Җилбәзәкләр кавеменә мөкиббән дөнья, миңа калса, һичкайчан камил дә, ипле дә була алмый.

Артистларча киенергә тырышалар, дигәннән. Халык, яшьләр соңгы елларны ертык чалбар киеп йөрергә гадәтләнде. Аны хиппилардан чыккан дисәләр дә, ул моданы популярлаштыруда кайбер музыкаль төркемнәрнең дә олы роль уйнаганлыгы мәгълүм. Урамда очраган умырык тезгә карау белән аның хуҗасына ямаулык сузасы, «Берүк киемеңне тәртипкә китерә күр, сеңлем яисә ханым», – диясе килгән чаклар еш була. Аек мантыйк бөтенләй ял итә ертык джинсы дигәндә. Ул гынамы, күз алдына андый галәмәтнең дәвамы да килә: бераздан халык күгәреп беткән, яньчелгән, тишелгән автомобильләрдә чаба башлый, тагын күпмедер вакыт үтүгә кыйшайган, ярым җимерек йортларда яшәү модага керә һ.б. Фантазияне дәвам итәсе килми, чөнки ычкынганнар цивилизациясе турында төшерелгән фантастик кино сценарие килеп чыга. Ертык ыштаннан чыккан нәтиҗә дә дөнья җитешлектән акылдан язуга, затсызлануга барып тоташа бит.

ОЧУ ГЫНА ТҮГЕЛ

Үзеңнеке – үзәктә. Соңгы арада бу фикерне еш ишетергә туры килә. Казанда узган Машина төзелеше оешмалары координацион советының X утырышында да еш яңгырады ул. Анда авиатөзелеш тармагында импорт алмаштыру турында сөйләштеләр. Утырыш бу көннәрдә башкаланың «Казан ярминкәсе» күргәзмәләр мәйданында узучы «Авиакосмик технологияләр, заманча материал һәм җиһазлар» дип исемләнгән авиация форумы кысасында үтте.

Утырышта катнашкан белгечләр фикеренчә, бүген авиация техникасы төзегәндә кулланылган зур булмаган кайбер компонентларны да үзебездә җитештерә башларга кирәк. Күп кенә оешмалар бу максатны тормышка ашыруда саллы гына эшләр башкарган да инде. Уралның авиация заводы, әйтик, бу урында ДА-42Т очкычын мисалга китерә ала. Очучыларны өйрәткәндә кулланыла торган әлеге самолетны төзегәндә кулланылган барлык җиһазлар да үзебездә җитештерелгән.

– Безнең күп кенә проектларда чит ил оешмалары катнаша иде. Килеп туган вазгыять аркасында җиһазлар базарын яхшылап өйрәндек һәм алар арасында үзебездә җитештерергә кирәк булганнарының исемлеген төзедек. Авиация техникасы төзегәндә кулланылган җиһазлар базары моннан биш ел элек булганы белән чагыштырганда күпкә яхшырак – төрлелек ягыннан бик нык алдыра, – ди Уралның авиация заводы вәкиле Антон Сафронов.

«Вертолеты России»

«Ансат» вертолетының конструкторлык бюросы да, вазгыятькә җайлашып, якын киләчәккә зур максат куйган. 2024 елда базарга тулысынча үзебездә җыелган «Ансат» вертолетын чыгарырга җыена алар. Бюро җитәкчесе Алексей Гарипов сүзләренә караганда, аны җыйганда кирәкле күп кенә детальләрнең аналогы булдырылган инде. «Импорт алыштыру сәясәтендә без «булганны күрә бел» дигән кагыйдәгә таянабыз. Шуңа күрә булдыра алган кадәр базардагы үзебездә җитештерелгән компонентларны гына кулланырга тырышабыз», – ди җитәкче.

Якын киләчәктә Татарстанда станок төзү заводы да пәйда булмагае. Ник дигәндә, утырыш барышында «Ростех» дәүләт корпорациясенә кергән «Механика» холдингы генераль директоры урынбасары Эдуард Бешкарев оешманың Татарстанда нәкъ менә шундый завод булдырырга теләвен әйтте.

– Татарстанда елына ким дигәндә 200 станок җитештерәчәк завод төзергә тәкъдим итәбез. Сезнең машина төзү кластеры иң көчлеләрдән санала, әмма станоклар җитештерелми, – диде ул үз чыгышында.

Аның бу фикерен утырышта катнашкан Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко да куәтләде. Бер белән генә чикләнмичә, Татарстанда берьюлы шундый дүрт завод төзергә тәкъдим итте ул. Бу фикер Бешкаревның күңеленә дә хуш килде. Олег Коробченко станоклар җитмәүне республика авиазаводларының авырткан урыны дип белдерде.

– Бездәге барлык авиазаводларда йөреп чыктым. Барысы да очкыч төзегәндә станокларга кытлык булудан зарлана. Күп кенә заводлар җиһазлар җитмәүне дә искәртә. Җитәкчеләр элеккеге оешмаларга барып, кайчандыр шундый станоклар торган урында полиэтилен астыннан нәрсә дә булса табарга өметләнә, – ди министр.

Татарстан Президенты ярдәмчесе Равил Зарипов исә тәкъдим турында республика җитәкчелегенә дә сөйләргә киңәш итте. «Бу – бик мөһим мәсьәлә», – диде Зарипов.

Олег Коробченко республикада бөтен завод, фәнни институт һәм җитештерүче оешмаларны берләштергән авиация кластеры булдырырга кирәклеген дә искәртте. Билгеле булганча, быелның апрелендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Татарстан сәүдә һәм сәнәгать министры Денис Мантуров «Алабуга» махсус икътисади зонасы базасында шундый кластер булдыру турында фикер алышкан иде инде. Ул чакта республика җитәкчесе, композит, автокомпонент, полимерлар эшкәртү юнәлешендә импорт алмаштыру проектлары тормышка ашырылачак, дигән иде.

Сүз уңаеннан, «Казан ярминкәсе» мәйданында узган форумда «түгәрәк өстәл», утырышлардан тыш, махсус күргәзмә дә эшләде. Анда Россиянең өч төбәгендә эшләп килүче 21 оешма үз эшләнмәләрен тәкъдим итте. Биредә яңа төр очкычларның кечерәйтелгән модельләре, Россиянең авиатөзелеш тармагында кулланылган технологияләр тәкъдим ителде. Импорт алмаштыру мәсьәләсеннән тыш форумда инженерларга белем бирү, авиация тармагын үстерү, бу өлкәдәге яңа җитештерү технологияләре, авиатуризм турында да фикер алыштылар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Иң көчле корал – сүз

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Иң рәхмәтле мизгел сәхнәгә Васил Гарифуллин күтәрелгәч булгандыр. Хөрмәт итеп, залдагы һәр журналист аягүрә алкышлады остазны. Ни гаҗәп, машина кадәр машинага лаек булган Васил әфәнде үзенең мондый зур бүләк белән кайтасына ышанмаган. Ул бу хакта белмичә килгән. Сәхнәгә чыккач, каушап та китте. Баштарак үзенә булган хөрмәткә аптырап, залда тагын да лаеклыраклар барлыгын әйтеп куйды. «Әгәр алдан сиздергән булсагыз, костюм кияр, галстук тагар идем. Көтелмәгән бүләк булды бу. Мин аны үземә генә түгел, журналистлар әзерләүче остазларга булган хөрмәт билгесе дип кабул итәм», – диде ул.

Җиңүчеләргә килгәндә, «Һөнәрдә иң яхшысы» булып «Татарлар» газетасыннан Гөлназ Шәйхиева, «Яңа Гасыр» ТРК журналисты Михаил Любимов, «Татар-информ» корреспонденты Гөлнар Гарифуллина табылды. «Журналистикага тугрылык өчен» номинациясендә «Татарстан» журналыннан Әскәр Сабиров, «Яңа Гасыр» ТРКсеннән Инсаф Абдуллин җиңүче булды. Махсус номинацияләр дә бар иде. «Татарстан Республикасында туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын иң яхшы яктырту» махсус номинациясе бүләге «Ватаным Татарстан» газетасына эләкте.

Хезмәттәшебез, танылган язучы Марат Кәбировка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнең күкрәк билгесен тапшырдылар. Баш мөхәррирнең икътисад буенча урынбасары Илсөяр Вәлиуллина Россиянең Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Гөлгенә ШИИҺАПОВА

Сан

Быел «Бәллүр каләм» бәйгесенә 1600 иҗат эше килгән. Шуларның 718е – рус, 978е – татар телендә. Иң күп гаризалар «Һөнәрдә иң яхшысы» номинациясенә килгән, анда 444 эш кабул ителгән. Бәйгедә Татарстаннан гына түгел, күрше Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Чиләбе өлкәсеннән дә катнашканнар.

САБЫЙ ФАТИРЛЫ ИТӘ

Җәһәт әңгәмә

Татарстанда ана капиталыннан файдаланучы гаиләләрнең 80 проценты бу акчаны торак шартларын яхшырту өчен куллана. Әйтергә кирәк, аны кредит рәсмиләштерү юлы белән фатир сатып алу өчен генә түгел, ә бәлки йорт төзү, булганын үзгәртеп кору, фатирны өлешләп түләп алу өчен дә файдаланырга мөмкин. Бигрәк тә акча белән бәйле эштә бәхәсләр бер-бер артлы туып кына тора. Укучыларыбыз да бу җәһәттән еш шалтырата.

Сорауларга җавап бирү йөзеннән, без Татарстан Росреестрының күчемсез милекне дәүләт теркәве бүлеге җитәкчесе Энҗе МӨХӘММӘТГАЛИЕВА белән сөйләштек.

:: Энҗе Исмәгдановна, торак шартларын яхшырту буенча ана капиталын кайсы очракларда кулланырга мөмкин?

– Бары тик ана капиталы акчасына гына торак сатып алырга теләгән кешегә бу хакта балага өч яшь тулгач кына сүз алып барырга мөмкин. Әмма фатир сатып алу яки йорт төзелеше кредит алу хисабына эшләнсә, акчаны бала тугач (уллыкка алгач) ук кулланырга була. Гаризаны кредит белән тәэмин итүче банкка язсаң, отышлырак, чөнки бу очракта Пенсия фондына мөрәҗәгать итүнең кирәге калмый. Банк кирәкле документларны җирле Пенсия фондына электрон каналлар аша үзе җибәрә. Эшнең барышы белән Пенсия фондының рәсми сайтында танышып барырга мөмкин булачак.

:: Торак шартларын тәгаен ана капиталы белән яхшыртырга уйлаган кешегә иң уңайлысын ничек сайлап алырга?

– Монда төрле юнәлешләрне карарга мөмкин. Яшәргә бөтенләй урыны булмаган кеше, әлбәттә инде, беренче чиратта фатир сатып алу яки йорт төзелеше башлауны кулдан ычкындырмаска тырыша. Инде шәхси йорты булса, аны сипли. Үзгәртеп корулар алданрак эшләнгән булса, чыгымнар өчен компенсация алу юлын эзли. Зуррак мәйданга ия буласы килгәннәр, кредит яки заём алып, башлангыч кертемне түли. Алар алданрак алынган булса, ана капиталын бурыч түләү өчен тотарга да мөмкин.

:: Без ана капиталы ярдәмендә үзгәртеп кору эшләре дип сөйләшәбез. Бу очракта ниләр күздә тотыла? Мөгаен, үтәлергә тиешле нинди дә булса шартлар да бардыр?

– Бу – шәхси йортның мәйданын арттыру дигән сүз. Ягъни мәсәлән, йортка янкорма, өстәмә кат төзү, чорманы мансарда итеп көйләү булырга мөмкин. Төп шарт – бу эшләрне башкарганда мәйдан иң ким дигәндә бер учет нормасы күләменә артырга тиеш. Торак пунктларның нинди булуына карап, әлеге норма 10нан алып 18 кв. метрга кадәр җитә. Шунысын да истә тотарга кирәк: үзгәртеп кору өчен башта сертификаттагы сумманың 50 проценты гына бирелә. Ә 6 айдан, эшләнгән эшләргә исәп-хисап ясалгач, калганы да тапшырыла.

:: Күчемсез милек кем исеменә һәм нинди срокка рәсмиләштерелергә тиеш?

– Ана капиталын кулланганда, күчемсез милек гаиләнең барлык әгъзаларына да рәсмиләштерелә. Әмма законда башта сертификат алган кешегә рәсмиләштереп, соңыннан милекне барлык гаилә әгъзаларына теркәү мөмкинлеге дә каралган. Моны Пенсия фондыннан акча күчерелеп, 6 ай үткәч тә эшләргә кирәк. Теркәү өчен документлар бирер алдыннан, һәр милекченең өлеше билгеләнгән булырга тиеш.

:: Ә ул өлешләрне ничек дөрес итеп билгеләргә?

– Әгәр фатирның бер өлеше генә ана капиталына сатып алынса, өлешләрне тәгаенләү өчен милек урнашкан территориянең нотариусына мөрәҗәгать итәргә һәм килешү төзергә кирәк. Торак тулаем ана капиталына сатып алынган очракта исә, өлешләрне нотариустан башка, язмача килешү төзеп кенә дә билгеләргә мөмкин.

:: Һәр гаилә әгъзасына бу өлешләр нинди күләмдә билгеләнә?

– Өлешләрнең күләмен билгеләү буенча законда нинди дер махсус нигезләмәләр юк. Бу үзара килешү юлы белән хәл ителергә тиеш. Тик, әйтергә кирәк, бәхәсләр чыгып, судка барып җиткән эшләр дә шактый. Бу очракта фатирның ана капиталына алынган өлеше гаилә әгъзалары арасында тигез итеп бүленә.

vk.com

:: Ана капиталын торак өчен кулланырга теләп мөрәҗәгать иткәндә, кире кагу очраклары бармы?

– Булгалый. Мәсәлән, документлар дөрес рәсмиләштерелмәсә, фатир яшәү өчен яраклы булмаса. Чыннан да, әгәр сатып алынасы торакка капиталь ремонт таләп ителсә, бернинди уңайлыклары булмаса, бу бит инде торак шартларын яхшырту булмый. Шуңа күрә ана капиталына сатып алырга ниятләнгән фатирларны башта www.reformaqkh сайтында һәм тузган йортлар реестрында тикшерәбез. Йорт сатып алырга теләгән очракта, җирле үзидарә органнарына хәбәр итәбез. Яшәү өчен яраксыз торак сатып алу очраклары булса, хокук саклау органнарына хәбәр итәбез. Әгәр дә ана капиталы максатчан кулланылмый икән, ул кире кайтарылырга тиеш. Законда каралмаган башка әйберләргә тотылса, җинаять эше булып санала.

:: Ана капиталы алу өчен бирелгән гариза нинди вакыт эчендә карала һәм акча кайчан күчерелә?

– Документлар пакеты белән бергә бирелгән гариза 10 көн эчендә карала. Кайбер очракларда 20 көнгә кадәр дә сузыла. Әмма шуннан артмаска тиеш. Шушы вакыт эчендә гариза каралып, я акча бирергә, я, сәбәбе күрсәтелеп, кире кагарга дигән карар чыгарыла. Карар уңай булса, акча биш көн эчендә күчерелә.

2022 елда бирелүче ана капиталының күләмен тагын бер кат искә төшерик әле.

– 524527 сум 90 тиен – ана капиталына хокуклары 2021 елның 1 гыйнварына кадәр булган гаиләләр һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан соң беренче балалары туган (уллыкка алынган) гаиләләр өчен.

693144 сум 10 тиен – 2021 елда икенче балалары туган (уллыкка алынган) гаиләләр һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан икенче һәм аннан соңгы балалары туып (уллыкка алынып), 2020 елның 1 гыйнварына кадәр өстәмә дәүләт ярдәме буенча чараларга хокуклары булмаган гаиләләр өчен.

Шунысын да искәртеп китәм: ана капиталы бер генә тапкыр бирелә. Аның яраклылык срогы юк, салымнан азат ителгән. Бу программа 2026 елга кадәр озайтылды. Ана капиталына сертификатны теләсә кайсы вакытта кулланырга мөмкин.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җыр эзлик бу тормыштан

Оныттың син гармуныңны,
Эчкә йоттың моңыңны.
Яшердең иң саф хисеңне,
Тынлык сарды кичеңне.

Ә гармунның бар зар-моңы
Түгелергә тулышкан.
Елатмыйк гармуннарны ла,
Җыр эзлик бу тормыштан.

Гармуның кулыңа алсаң,
Киңәер офыкларың.
Җырлы итеп үткәрерсең
Сагышлы минутларың.

Уйнап җибәр гармуныңны,
Дуслар бергә җыелсын.
Белик яшәүнен кадерен,
Тойыйк тормыш җылысын.

Фәнүрә РӘХИМОВА

Кая тәгәрибез?

Нинди генә борылышлар ясамый тормышыбыз. Бүген БДИ биремнәрен тапшыру өчен башлангыч сыйныф белеме дә җитә. Ишеткәнем бар: хәтта журналистика бүлегенә килгән студентларның язма эшләрен тикшерсәң, дәфтәр бите чуар төскә керә икән. Ун сыйныф тәмамлаган яшьләр үз язмаларын укый алмый, китаптагы җөмләләрнең мәгънәсенә төшенми. Сәбәбе – тел-әдәбият дәресләрендә уку-язарга түгел, БДИга бирелә торган шакмакларга тамга куярга өйрәнүдән. Дөрес, укучыларның халыкара олимпиадаларда җиңеп чыгу очраклары бар. Әмма моның серле ысул белән алып барылуы мәгълүм булды. Монда катнашучы бер укучы, математикадан чыгыш ясау өчен, бүтән фәннәрне бөтенләй «онытып» торганын бәян итте. Аның белән махсус укытучылар даими шөгыльләнгәннәр.

Мәгариф өлкәсендә нинди генә стандартлар кертеп карамадылар, барып чыкмады. Чөнки һәр баланың – үз башы, барлык балаларны да бер стандартка туплау – барып чыкмый торган эш. Патша заманында ук җәмгыятьнең терәге булган укытучының бернинди кадере юк. Хөкүмәт, укытучыларны карусыз эш атына тиңләп, аларның өстенә елдан-ел кәгазь катламы өя. Бу хәлгә түзә алмаган укытучылар эштән китү ягын карыйлар. Бигрәк тә рус теле укытучылары, физика, математика белгечләре китә. Ата-аналар, балалар бу фәннәр белән кызыксынмый. Бүгенге җәмгыятьтә юрист булу, сәүдә итү кулайрак.

Хөкүмәт башлыклары мәгариф өлкәсендәге уңышсызлыкларны милли телдә укытуда күрделәр. Янәсе, милли телләр рус телен кысрыклый, рус телендә укымаган балаларның башлары юньләп эшләми. Әгәр шулай икән, нигә рус балалары язма эшләрне кып-кызыл хата белән язалар? Дөресен әйткәндә, рус теле үзе дә үсеш кичерми. Аның чит телләр белән чамасыз чуарлануыннан галимнәр дә канәгать түгел. Мәгариф өлкәсендәге кризисны илдә бара торган сәяси һәм икътисади кризис белән дә бәйләп карамыйча булмый. Белем алган яшьләрнең төркем-төркем булып чит илгә омтылуын ничек аңлатасың? Мин белгән уннан артык кыз бүген Англия һәм Америкада хезмәт итә. Төркиягә киткәннәрне санап бетерерлек түгел. Икътисадчылар мондый хәлне гыйльми капиталның читкә агуы дип бәялиләр. Хәтта зур-зур түрәләрнең дә балалары чит илдә гомер сөрә.

Соңгы елларда мәктәп программасында физика, математика фәннәре 30 процентка кимегән. Шәхсән мин үзем җитмешенче елларда 8 нче сыйныфта атнага өчәр сәгать физика дәресләре алып бардым. Бүген ул атнага ике генә сәгатькә калган. Ә менә чит тел дәресләре бермә-бер арткан. Мин өч телгә басым ясап укытуны буш хыял дип исәплим. Тел өйрәнеп кенә галим булып булмый. Физика, математика укытучыларының җитмәве моңа да бәйле түгел микән әле?

Әнәс ЗАРИПОВ.
Казан

Таянычым

Бу 1954 ел иде. Беркөнне төш күрәм. Эштән кайттым, имеш, ә өйдә ашарга бернәрсә дә юк. Куркып уянып киттем. Хәер, күп уйланып йөрергә туры килмәде, Нәҗип килеп керде. Ул елмаеп кына: «Күптән әйтәсе килгән сүземне әйтергә килдем. Әйдә, бергә булыйк. Өйләнешик!» – ди. Мин гаҗәпкә калдым, ни диярга дә белмәдем. Ә ул: «Нигә шулкадәр аптырап калдың, без бит инде күптәннән бер-беребезне беләбез, яшебез дә җиткән», – ди. Мин аңа: «Ашыккан ашка пешкән, диләр бит, уйлашыйк әле», – дидем.

Беләм, әни каршы килмәс, чөнки ул аны гел мактап, якын күреп йөри иде. Икенчедән, егет минем күңелемә игелекле булуы белән дә кереп калган. Бервакыт шулай үткәннәр турында сөйләшеп утырабыз. Ул, үкенеп: «Сезнең шундый авыр тормышта яшәгәнегезне белмәдем шул, шахтадан посылкалар салган булыр идем», – дигән иде. Шул вакытта аның сүзләре мине посылка алганнан да ныграк шатландырды. Чөнки мин үземнең ниндидер бер таянычым бар сыман хис иттем. Әтисез ятим үскәнгә, йөрәк ярама бер тамчы дару салган кебек булган иде ул. Өченчедән, ялгышмаммы, дигән сорау да борчый. Озакка сузып тормадык: сөйләштек-уйлаштык та, ике якның да ризалыгын алып, өйләнешергә булдык.

Сөйләшү буенча, Нәҗип мине иртәнге сәгать 4тә ат белән килеп алырга тиеш. Фанерадан ясалган бер бәләкәй яшел сандыгым бар иде, шуңа бирнә әйберләремне тутыра башладым. Ситсыдан тегкән чаршау, аннан чәчкәләп-чәчкәләп чиккән җәймә, аның өстеннән караватка җәяргә бәйләнгән челтәр, биш тәрәзәгә биш пәрдә, берничә сөлге салдым һәм ике яңа мендәр бәйләп куйдым. Хаҗип абыйсы белән килеп, мине үзләренә алып кайтып киттеләр. Анда безне каенатам Фәләхетдин, каенанам Факиһә һәм каенсеңлем Камилә каршы алдылар. Өйгә килеп керү белән тәмле аш, коймак исләре борынга килеп керде. Беренче күрүдә үк алар – мине, мин аларны үз иттем һәм гомер буе шулай яшәдек. Ашагач, эчкәч, әти барыбызга да карап: «Балалар, бүген безне бик күп эшләр көтә. Аллаһы теләсә, сезгә бүген никах укытырбыз, ЗАГСка да барып кайтырсыз», – диде. Без: «Әмин», – дидек. Язылышып кайтканда, өйгә тәмле бәлеш исләре таралган иде инде. Озак та үтмәде, ашка кешеләр җыела башлады, мулла да килеп җитте һәм безгә никах укыдылар.

Менә шул вакытлардан соң бергә яшәвебезгә бик күп еллар үтте. Ике малай, бер кыз үстердек. Балалар хәсрәте күрмәдек.

Миңзифа ХӨСНЕТДИНОВА.
Әлмәт

ИТЕКЛЕ ЧАҢГЫДАН – ЗУР СПОРТКА

Җиденче сыйныфка кадәр мин Буа районы Адав-Толымбай авылында белем алдым. Аннан соң укуымны Буа шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге мәктәбендә дәвам иттем. Әлеге уку йорты мине чын-чынлап тормышка әзерләде дисәм дә, ялгыш булмастыр. Биредә белем бирүче һәрбер укытучыга рәхмәтем һәм хөрмәтем чиксез.

Бигрәк тә физкультура дәресләре хәтердә сакланып калган. Укытучыбыз Сәхәп Курамшин – сугыштан яраланып кайткан офицер – киң җилкәле баһадир булып истә калган (мәрхүм инде, авыр туфрагы җиңел булсын). Аның янында һәрберебез көчле булып күренергә тырыша иде. Ул безне чын ир-егет итеп тәрбияләүгә зур өлеш кертте. Сәхәп Шиһап улының тар гына мәктәп коридорында үткәргән дәресләре бүген дә күз алдында. Безне тезеп бастыра да:

– Әйдә, Шәмиев, күрсәт әле үзеңне, – дип команда бирә. Ә миңа шул гына кирәк тә: яшен тизлеге белән канаттан менеп тә китәм. Мәктәп коридорындагы дәресләр кыш җиткәнче генә. Беренче кар төшүдән башлап көннәр язга авышканчы, мәктәп янәшәсендә чаңгы эзләре бетми иде. Кайвакыт укытучыбыз безне тауга, урман буена алып китә. Шулкадәр онытылып, яратып шуа идем чаңгыда:

– Балалар, дәрес тәмам, чаңгыларыгызны алып, кайту юлына атлый торыгыз, – дигән сүзләр ишетелгәч тә, тауга бер-ике менеп төшә идем.

Толымбайда без – итекле чаңгыда шуып үскән малайлар – биредә укый башлагач, ботинкалы чаңгыда шуучы егетләргә әйләндек тә куйдык. Ул елларда киләчәктә чаңгычы булырмын дигән уй башыма да килми иде. Нәкъ менә Сәхәп Шиһап улы биргән белем һәм тәрбия спортка мәхәббәт уятты дисәм дә, дөрес булыр. Укытучым чаңгы шуу алымнарын гына өйрәтеп калмады, тормышта үз юлымны табарга этәргеч бирде. Аның биргән киңәшләре әле дә (инде туксанынчы яшем белән барам) минем өчен бик кадерле.

Яши-яши шундый фикергә килдем: гомерне бит еллар билгеләми икән. Иң мөһиме, күңелдә яшәү дәрте булсын. Югары белем алып, тормышыма бик рәхмәтле булып, Арчада гаилә кордым, балалар үстердек. 56 еллык хезмәт стажым мәктәптә, педагогия көллиятендә физкультура укытучысы буларак үтте. Бик рәхәтләнеп әле дә шәһәребездә, республикабызда үтүче чаңгы ярышларында, марафоннарда катнашам, спортның барлык төрен дә яратам. Җәйге спартакиадалардан да читтә калмыйм. Әле бу елның 12 февралендә узган «Россия чаңгы юлы – 2022» ярышында район башлыгы: «Менә безнең район, республика данын яклаган

чаңгычыларыбыз», – дип, яшьләрне бездән үрнәк алырга чакырды (ел да әлеге ярышта беренчелекне биргән юк). «80 яшьлекләр арасында сезгә тиңнәр юк», – дип, рәхмәтен дә аерым белдерде ул.

1965 елда Кемерово шәһәрендә үткән бөтенроссия «Уңыш» чаңгы ярышында республиканың җыелма командасы составында 50 чакрымга чаңгыда чабып йөри алыр идемме икән, әгәр Сәхәп Курамшин укучысы булмасам, дип уйлап куям. Тәмамлап чыгып киткәнгә алты дистәдән артык гомер узса да, очрашканда мәктәп еллары искә төшә, һаман да сагындыра, юксындыра. Еллар үтә, без олыгаябыз, ә күңел никтер бер дә үзгәрмәгән кебек. Инде сыйныфташларым да салмак хәрәкәтле, ипле, акыллы, сабыр булып өлкәнәеп киләләрдер. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә хәерле бәрәкәтле гомер насыйп итсен!

Җәгъфәр ШӘМИЕВ,
Татарстанның атказанган укытучысы, халык мәгарифе отличнигы. Арча

ИСКИТӘРЛЕК

Авылга яшь кенә егет мулла булып килгән! Ничек инде шундый да яшь мулла була, дигән гаҗәпләнү катыш аптыраулы сүзләр ишетелгәнгә дә 20 ел узган икән. 2002 елда авылыбызда мәчетләр төзелеп, халык иманга юл тоткан елларда районга имам-мөхтәсиб булып күченгән Илһам хәзрәт урынына япь-яшь, 19 яше тулып кына килүче Илфат хәзрәт килде. Минем сүзем мәхәлләбезнең хәзер инде зур мактауга ия, мөхтәрәм имамы Низамов Илфат Дамир улы турында булыр.

«Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы» исемендәге Казан Югары Мөселман мәдрәсәсен тәмамлаган егет авылга яңа сулыш алып керде. Яшь булуына карамастан, үзен өлкәннәрдән дә, кечеләрдән дә яраттыра алды. Үзенең тик тормас табигате белән, оста кулы, тәмле теле белән ят авылда бик тиз генә үз булып китте. Мәчеткә балаларны җәлеп итү өчен, алар белән төрле бәйгеләр уздыру дисеңме, бер төркем мәчеткә йөрүче балаларны җыеп, табигатькә чыгу дисеңме – ни генә уйлап тапмый хәзрәт.

Көннәр уза, Илфат хәзрәт хезмәткә дип килгән җирендә үзенә тиң ярын – авылыбыз кызы Энҗене очрата. Матур гына очрашып йөргәч, алар тормыш корып җибәрделәр. Яшь гаилә әби-бабай белән бергәләп, авылда тулы канлы тормыш алып бара башлый. Гаиләне ныгытып, матурландырып, уллары Ислам, Рамазан, кызлары Гүзәл туды. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, диләр бит, балалары да тел ачылганнан намаз укып, догалар укып, төрле бәйгеләрдә катнашып үсә аларның. Спортта да, укуда да, иҗатта да сынатмыйлар. Гаиләләре белән дә бәйгеләрдә катнашалар.

«Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» мәкаленең асылын үзенә туплаган Илфат хәзрәт. Дингә хезмәт итү белән берррәттән, нинди генә эшләр эшләми ул. Ул – уйлап табучы да, тракторына үз куллары белән бәрәңге утырткыч ясап, авыл халкының кул эшен дә киметте. Бәрәңгене хәзер Илфат хәзрәт утыртып бирә. Бик тәмле бал ашыйм дигән кеше дә Илфат Дамир улына мөрәҗәгать итә. Умарталары туган авылы табигатенә сыенган, аларны карарга җитешә торган умартачы да ул. Үзе белгән һәр эшкә инде буй җитеп килүче Исламны да өйрәтә, улы – аның зур ярдәмчесе. Авылыбыз урамы буйлап китсәгез, иң матур ясалган капкалар кем кулыннан узган икән, кем эше икән бу дип һич тә аптырамагыз. Мондый сокланырлык матурлыкны Илфат хәзрәт кенә тудыра ала. «Куллары ннан гөл тама», «алтын куллы» дигән сүзләр нык туры килә аңа. Тимерне дә буйсындыра, агачны да җанландыра торган кеше безнең авыл имамы! Аның остаханәсенә керсәң, нинди генә эш кораллары юк! Өй эченә сыйфатлы ремонт кирәкме, әллә тыштан өйне матурлап төрәсеме – һич шикләнмичә, Илфатка мөрәҗәгать итеп була. Каян җитешә дә, каян көч табадыр, дип шакката торган. Барлык шул кулы белгән эшләре өстенә төп вазыйфасын да җиренә җиткереп үти, үтемле вәгазьләрен халыкка җиткерергә дә вакыт таба ул. Төп нигездән ерак түгел генә бик матур йорт күтәреп куярга да җитешә, тормыш иптәше Энҗе белән балаларын тәрбияләүгә дә үз өлешен кертә, аларны үз үрнәкләрендә ярдәмчел, гадел, ягымлы булырга өйрәтәләр.

Дөньяви гыйлемне укытучы таратса, дини гыйлемгә омтылышны имамнар тәрбияли. Аларның олы хезмәтен ияр үчеләре белән дә бәялиләр. Ә безнең авылда мәчет гөрләп тора, кайчандыр кеп-кечкенә килеш Илфат абыйларыннан гыйлем эстәгән малайларның инде берничәсе үзләре мөхтәрәм дини гыйлем ияләре, Татарстанның төрле төбәкләрендә дин әһеле, мәдрәсәдә мөгаллим, мәдрәсә шәкертләре. Дөньяви гыйлем алучылары да, инде төрле өлкәләрдә хезмәт куючылары да киңәшкә кайталар аңа, вакытлары булуга, элеккечә җыелышып табигатькә чыгалар, кунакка кайткач, намазга мәчеткә юл алалар. Бәхетле безнең мәчеткә гыйлем эстәргә йөрүче авыл балалары: аларны Илфат абыйлары ел саен кая булса да экскурсиягә алып китә: әле изге Болгар җирен, я Иҗаудагы зоопаркны күреп кайталар, я Алабуга музейларын йөреп кайталар. Шуңа да, бәлки, мәчеттә балалар саны артып торадыр. Иренмәс Илфат хәзрәт автобусын да, финанс ягын да җайлый, бөтен рөхсәт кәгазьләрен дә юллый. Районкүләм нинди генә дини чаралар уздырсалар да, сәхнәдә безнең мәхәллә балалары чыгыш ясамый калмый. Балалар белән эшне ул мәчеттә генә түгел, мәктәптә дә алып бара, ел дәвамында укучылар белән «Тәрбия дәресе» уздыра. Укучыларны тәрбияләүгә зур өлешен кертә.

Бүген инде ир уртасы булып килүче имамыбыз үзенең оста вәгазьче, ярдәмчел, тырыш, уңган булуы белән бик күп мактау сүзләренә лаек. Низамов Илфат хәзрәт җитәкләгән Мамадыш мөхтәсибәте Яңа Комазан авылы «Рәшидә» мәчете Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте оештырган республикакүләм «Изге әманәт» бәйгесендә «Яшьләр өчен татар телле проектларны тормышка ашыра торган иң яхшы мәчет» номинациясендә җиңүче дип табылды һәм 120000 сумлык сертификатка лаек булды. Безнең киләчәк, милләтебез киләчәге, динебез киләчәге – бүгенге балалар, яшьләр кулында! Аларны тәрбияләүдә мәктәп белән беррәттән дин әһелләребез дә ныклап шөгыльләнә, уртак тел табыла икән, димәк, киләчәк ышанычлы кулларда булачак дигән зур өмет бар. Арабызда Низамов Илфат Дамир улы кебек имамнарыбыз булу сөендерә!

Илфат хәзрәт гаиләсендә бу көннәрдә зур куанычлы вакыйга – гаиләдә дүртенче бала, сөйкемле кызчык дөньяга аваз салды. Бәхетле гаиләгә алга таба да ышанычлы әти ышыгында бәхетле тормыш итәргә язсын, дигән теләктә каласы килә.

Гөлназ ГӘРӘЕВА.
Мамадыш районы
Яңа Комазан авылы

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Әшрәфҗанов** Рәдив Шамил улы; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының финанс бүлеге башлыгы урынбасары **Данилова** Лидия Алексеевна; Чистай муниципаль районының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгы **Иванов** Дмитрий Алексеевич; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесе урынбасары **Полях** Галина Ивановна; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты аналитика бүлеге баш киңәшчесе **Рубцова** Мария Олеговна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы» филиалы мәгълүмати технологияләр бүлеге фотокорреспонденты **Исхаков** Солтан Нурислам улы; «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Яңа Чишмә хәбәрләре» филиалы баш мөхәррире – җитәкчесе **Мусин** Азат Вәлиҗан улы; хезмәт ветераны **Хөсәенов** Рөстәм Гизетдин улы; хезмәт ветераны **Юнысов** Николай Васильевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы тезелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы «Татарстан» журналы редакциясе» баш мөхәррире – җитәкчесе **Вафина** Татьяна Николаевнага; «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте телевидение телеоператорлары бүлеге башлыгы **Вафин** Илгиз Фрат улына; «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы «Арча мәгълүмат үзәге» баш мөхәррире – җитәкчесе **Насыйбуллин** Исрафил Рәхмәтулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

САЙЛАУДА КАТНАШУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, Ибраһимов һәм Пионер бер мандатлы округлары буенча агымдагы чакырылыш Дәүләт Советына өстәмә сайлау үткәрү өчен сайлау кампаниясенең агитация чоры алдыннан, теркәлгән кандидатларга басма мәйдан бирүгә жирәбә үткәрү турында белдерә.

Жирәбә, Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе белән берлектә, сишәмбе – 9 августта Казанның «Московский» мәдәният үзәгендә (элекке Урицкий исемендәге мәдәният йорты, адресы: Академик Королев урамы, 47 нче йорт) уздырыла. 10.00 сәгатьтә башлана.

Жирәбә беркетмәләре нигезендә, 13 августтан 9 сентябрьгә кадәрге чорда бушлай язмаларны бастырып чыгару графигы төзеләчәк. Шул ук вакытта сайлау алды агитациясен урнаштыруга килешүләр төзеләчәк. Шуңа күрә кандидатларның вәкаләтле вәкилләреннән үзләре белән тиешле документларын алып килүе сорала.

Исегезгә төшерәбез: бушлай мәйдан күләме 2019 елда узган алтынчы чакырылыш Дәүләт Советына төп сайлаудагы кебек билгеләнә. Һәр кандидатка агитация чорының беренче яки икенче, өченче яки дүртенче атнасында 6,2х7,5 үлчәмендәге ике модульне бастырып чыгару мөмкинлеге биреләчәк. Язмалар, гомуми блок белән, чәршәмбе көннәрендә басылып чыгачак.

Түләүле агитация бастыру өчен дә шундый ук күләм каралган. Аны, чәршәмбе саныннан тыш, заказчының теләгенә һәм редакциянең мөмкинлегенә карап, газетаның теләсә кайсы санында урнаштырып булачак.

Агитация материалларын урнаштыру шартлары һәм түләүле мәйдан бәясе турында тәфсилле мәгълүматлар газетабызның 5 июль санында (№ 94) тәкъдим ителгән.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы, Теләче районы ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе

БОРҺАНОВ Шамил Галимҗан улының

вафат булуы сәбәпле, тормыш иптәше Альмира ханымның, балалары Сирин, Алмаз, Азатның һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Мәрхүмнең урыны оҗмахта булсын, гаиләсенә һәм якыннарына Аллаһы Тәгалә сабырлык бирсен.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

ТОРТ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

Тарихта төрле нәрсәләрнең эволюциясе булган кебек, тортның да эволюциясе бар. Безнең балачак торты ул – өстендә чәчәкле-чуклы кремнар белән бисквит. «Әни, миңа чәчәклесен кисеп бир!» – дип кычкыра идек. Ул чакта торт бик тансык ризык иде, туган көннәргә генә эләкте. Өстендә берничә шәм яндыра идек. Галимнәр исәпләвенчә, еллар узган саен, туган көн торты яктырак яна ди.

Бисквит тортлардан соң яңа буын – бизе тортлар барлыкка килде. Алар бисквиттан югарырак тотты үзен. Чөнки күперебрәк торалар. Берәүләр бу ризыкны бик яратып ашаса, икенчеләр үзләрен һава ашаган сыман тойды, «пенопласт чәйнәде». Ә Татарстанда бу сериядән иң популяры нинди иде? Дөрес, «Татарстан» торты. Тәмлетамаклар, белеп торыгыз, дөньяда иң тазарта торган әйбер ул – чәй. Чөнки чәй белән һәрвакыт берәр тәмлүшкә ашыйсың.

Кайбер тортларга әллә нинди тарихи романтик исемнәр бирделәр. Бер-берсенә түгәрәк бизелар өеп куеп, өстенә крем агызгач, кондитер озак уйлап тормаган: «Графские развалины» дип исем кушкан. Берәү шундый тортны кибеттә күргәч, сатучыдан сорап куйган ди: «Бу торт сездә күпме тора?» «Ярты ел», – дип җавап биргән сатучы.

Танылган тарихи тортларның тагын берсе – «Наполеон». Ул да тортлар эволюциясендә классик торт-

vk.com

ларга алмашка килде. Райпо кибетендә «Наполеон» исемен атаган саен Бонапарт ага әйләнеп яткандыр. Ә, гафу итегез, Райпо кибетендә сатылмады бит ул. Бер мәзәк искә төште. «Сез кем?» «Мин – Наполеон». «Тәк, Ленин һәм Петр I булмәсенә билгелибез сезне». «Сез аңламадыгыз, мин – торт!»

Аннары «Медовик» барлыкка килде. Бик гади торт. Нинди чәчәк кирәк сиңа тагын! Тот та аша! Ул шулхәтле гади иде, аны кайбер хуҗабикәләр өйдә генә пешерергә күнекте. Диетада утыручы бер танышым ул чакта 4000 килокалория яндырган иде. Тортны духовкада онытып калдырып.

«Медовик»тан тагын да бизәксезрәк «Невский» пирогы бар. Аны хәтта торт дип атарга да җөрьәт итмәделәр. Эволюция дәвамында «Невский» пирогы әкренләп «Юбилейный»га әйләнеп куйды. Мин аны өйдә генә пешерер идем дә, E517 һәм E1452 дигән дирбияләрен каян аласын белмим шул.

Исем алыштыру дигәннән. Затлы гына бер кибеттә соңгы елларны «Бабушкин пирог» чыккан иде. Бик тәмле булса да, бәясе бераз «тешләде». Әмма конкурентлар йоклап ятмый. Тиз арада арзанрак бәягә тәкъдимнәр килеп чыкты. Һәм әбекәйне ничек кенә төрләндермәделәр: «Бабушкино», «Бабушка», «Бабушкинский».

Соңгы арада меренговый рулетлар һәм тортлар барлыкка килде. Моның нәрсә аңлатканын сүзлексез аңламассың да. Әмма социаль челтәрләрдәге зифа буйлы ПП-кызлар бик мактый аларны. Кызлар, бер лайфхак әйтәм сезгә. Әгәр дә тортны кисми генә ашасагыз, ул бер кисәк булып саналачак.

Бу эволюциядә һәрбер тортка аерым тукталсаң, бик күпкә китәр иде. «Птичье молоко», «Муравейник», «Шахмат» пирогы, «Киевский», «Сметанный», «Мишка на севере», «Монастырская изба», «Прага», «Зебра», «Черепаха»… Һәр гаиләнең – үз бәйрәме, үз гадәтләре һәм үз… тортлары. Әйдәгез, шул хөрмәткә бер чынаяк чәй! Тортны ничә өлешкә кисик? Сезгә кайсы җирен бирик? Чәчәклесенме?

Рус газетасында игълан:
Делаю выпечку, пироги на заказ. Дешево. Возможен торт.

БИЗМӘННӘР ҺӘМ БИЗНЕСМӘННӘР

- Бизнеска нигезләнгән дуслык дуслыкка нигезләнгән бизнеска караганда яхшырак.
- Безнең фирмада иң төп документ ул – Инструкцияләр төзү буенча инструкция һәм Графикларны тикшерү графигы.
- Бер алманы юып сатып, шуның акчасына ике алма алып бизнес ясап була, дип өйрәтүчеләр шуны оныта: боларны эшләгән арада бер алманы инде ашап куясың.
- Безнең эштә, гадәттә, ике проблема бар: юрист белән киңәшләшми төзелгән документ һәм юридик бүлек төзегән документ.
- «Бер миллион сумны ничек эшләргә?» дигән семинарны башлыйбыз. Аңлатам. Бу чарага билетның бәясе 1000 сум. Һәм бу залда 1000 урын...
- Минем кибет минуска эшли. Әмма аны япсам, нәрсә хисабына яшәрмен дип куркам.
- Безнең илдә эшмәкәр ике тапкыр бәхет кичерә: ИП ачканда һәм ИП япканда.

hr-portal.ru

Булган хәлләр

▶ «Алмаз Хәмзиннән урланган»

Алмаз Хәмзингә хезмәттәше шалтырата. Кайсыдыр әсәре белән кызыксына. «Синдә минем «Озак яшисегез килсә…» дигән китабым юкмы?» – дип сорый Алмаз абый. «Юк шул». «Алайса, минем янга кер, бүлмәдә генә карап торырга бирәм, алып торырга бирмим, ату югала». «Безнең хезмәт дәресе укытучысы Шамил абыйның бөтен чүкеч-пычкыларына «Украдено у Каюмова» дип язылган иде, Алмаз абый. Шулай итсәң, югалмый ул», – ди хезмәттәш. Алмаз абыйга бу идея бик ошый: «Миңа да бөтен китапларыма «Алмаз Хәмзиннан урланган!» дигән мөһер сугып чыгарга кирәк әле».

▶ Илдар Муллин чиратка куя

Танылган продюсер, татарча клиплар авторы, Гөлнара Тимерҗанованың элеккеге ире Илдар Муллин подъездга кереп бара. Кулында кармаклар. Күршесе очрый: «Сәлам, Илдар, балыкка бардыңмыни?» Илдар берни дәшми. 9 нчы катка кадәр җәяү менә болар. «Әйе», – ди Илдар. «Нәрсә әйе?» – ди күрше. «Балыкка бардым». «Мин сорау биргәнемне инде онытткан идем», – ди күрше. «Ә мин синең сорауны башымда чиратка куйдым», – ди Илдар. Бәрәкалла, дип уйлап куя күршесе, моның башы компьютер сыман икән, күпме сорау чиратта тора!

▶ Фәрит Мифтахов латина бии

Төрле җырчылар, биючеләр, музыкантлар утыра торган «Ватсап-төркем»нәр бар. Гадәттә, анда төрле концертларга, банкетларга кеше эзлиләр. «27 августка Кукмарага җырчы кирәк», «Лаеш районында узасы туйга биюче эзлиләр, бюджет фәлән мең сум» ише хәбәрләр була анда. Кайвакыт кызыклы хәлләр дә килеп чыга. «Латина биюче танышларыгыз юкмы? Телефонын җибәрегез әле» дигән үтенечкә берәү Фәрит Мифтахов телефонын җибәрде. Фәрит әфәндене конгресс вәкиле, эшмәкәр, хәтта клиплары булган җырчы дип тә белә идек. Әмма латина биюләрен оста башкаручы икәне күпләр өчен яңалык булды. Талантлы кеше һәр нәрсәдә талантлы, диләр бит. Әмма мактавыбыз ашыгыбрак булган. Бу телефон номерын язган кеше аны алдагы сорауга җаваплаган икән. Менә шундый мәзәк хәлләр китереп чыгара «Ватсап-төркем»нәр. Аның каравы бөтен кеше Фәрит Мифтаховның латина биюен күз алдына китереп өлгерде.

ИГЪТИБАР!

! Татарстан буйлап вертолетта 4 кешелек түләүсез сәяхәткә тагын ике кеше эзлибез. Киләсе шимбә иртән Казаннан очабыз, иртәнге ашны Зөя утравында ашыйбыз, шуннан Болгарга очабыз. Анда экскурсиядән соң ике сәгать Идел буйлап яхтада Алабугага кадәр йөзәбез, төшке аш шунда булачак. Кичке сигездә Казанга кире очып кайтабыз. Кемгә кызык, безнең белән элемтәгә керегез. Безгә вертолеты һәм яхтасы булган кеше кирәк.

Фотофакт

Пробегы ничәдер бит, еллары ниндидер бит, кредитка түгелдер бит?

Рифат СӘЛАХ

«КЕНӘР КЫЗЫ»НА

Шуыша кыш язга таба:
Төннәр суык, көннәр кызу.
Каян килеп кердең әле
Шигыремә, Кенәр кызы?!

...Кенәрне бер күргәнем юк,
Бигрәк матур авылдыр ул...
Ләбиб Лерон

Җәй шуыша көзгә таба,
Төннәр бөрку, көннәр кызу.
Каян килеп керде шигырь,
Ләбиб Лерон. «Кенәр кызы»?!

Кенәрне бер күргәнем бар,
Тик күрмәдем Кенәр кызын.
Анда кабат барып тормам,
Көннәр кызу, юллар озын.

Ләбиб абый күңеленә
Килеп кергән яз аенда
Кенәр кызларына юк шул
Бер юл шигырь язганым да.

Көннәр – Кенәр шәп рифмадыр,
Гүя ташкын, гүя давыл.
Ә кызларын күргәнем юк,
Үзе бигрәк матур авыл.

КЕСӘМДӘ

Минем сөю – йөрәгемдә,
Ә синеке – кесәңдә.
Игътибар итмисең миңа,
Чәчәк тотып килсәм дә.

Карамыйсың бер дә миңа,
Сөюемнән янсам да.
Синең йортың тирәсендә
Күпме карлар ярсам да.

Шигырь багышлап язсам да,
Аңламыйсың шул бер дә.
Сөюең кесәңдә йөри,
Ә син – минем күңелдә.

Карамыйсың, файда юк шул
Еласам да, көлсәм дә.
Карар идең, җилләр уйный,
Акчам юк шул кесәмдә!

КЫЗЫК ГЫЙШЫК

Шагыйрь ялган сөйли алмый,
Яратам, сөям, диеп.
Мин берәүне өзелеп-өзелеп
Яратам, сөям кебек.

Мин берәүгә гашыйк булдым,
Шуңа күңел җыр инде.
Мин берәүне өзелеп сөям
Әллә ничә ел инде.

Мин берәүсез яши алмыйм,
Мактанчык ләкин ярым.
Ул – бердәнбер мәхәббәтем,
Кояшым, аем, җаным!

Шагыйрь ялган сөйли алмый,
Яратам бигрәк үзен.
Ул кем диеп уйлыйсыздыр,
Ул үзем инде, үзем.

Мач әйткән!

Дени ДИДРО, француз фәлсәфәчесе
Тутыгып беткәнче таушалып бетүең хәерлерәк!

Дусларча шарж

Наил Галимов шаржы

Август ае килеп җитте,
Салават ае бу, брат!
34 нче тапкыр, ди,
Очрашу быел кабат.

Казаннарга килеп чык син,
Әйдә, җиктереп пар ат,
Эш кала, дип борчылмәле,
Калган эшкә – Салават!

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

ШӘЛЕ КЫЗЫКЛАРЫ

ПИТРӘЧ РАЙОНЫНДАГЫ ШӘЛЕ – РЕСПУБЛИКАДА ИҢ ЗУР АВЫЛ

«ДАҺИЛАР ПЕЛӘШ БУЛГАН»

Узган гасырның кышкы бер көне. Лаеш урман хуҗалыгы баш лесничий кабинетында Шәле – Пәрәү авылы кырыендагы катнаш урманнарны саклап, 17 ел каравылчы булып эшләгән Сафинның персональ «эш»ен тикшерәләр.

– Карагыз сез моңа, – ди баш лесничий, бармагы белән төртеп күрсәтеп, – көн саен эчә-эчә Сафинның баш түбәсендә инде чәче дә калмаган, тәмам пеләшләнгән. Нинди куе, бөдрә чәчле иде югыйсә.

– Ә, шулаймыни? – ди Сафин. – Әнә стенагызда Ленин эленеп тора. Ул да пеләш. Ул да эчеп пеләшләнгәнмени? Сез мондый сүзләрегез белән мине генә түгел, ә бөек юлбашчыны да хурладыгыз, мыскыл иттегез! Мин бу хакта «тозлап, борычлап» Мәскәүгә, ЦКга шикаять язып җибәрәчәкмен. Бик беләсегез килсә, җир йөзендә даһиларның күбесе пеләш булган.

Мондый җавапны көтмәгән баш лесничий бер мәлгә югалып кала. Әлеге сөйләшүдән соң Сафин тагын берничә ел урман каравылчысы булып эшли әле, әмма теге «нәрсәкәй»не тоткалавыннан барыбер ваз кичми.

АВЫЛ КУАСЫ

Еракта калган елларның берсендә партком секретарена Беренче чылтырата, фәлән көнне сезгә киләм, авыл мунчасын, авыл куасын сагындым, ди. Авылда эшнең кызу чагы, урак өсте, шуңа карамастан, әйткән вакытка барлык шартларын

китереп мунча ягалар. Тик менә куас мәсьәләсен генә хәл итеп булмый, берсе дә юньле итеп куас әзерли алмаган. Партком секратаре, Аллага тапшырып, шоферы Габдулланы Казанга шәһәр куасы алырга җибәрә.

Бик матур җирдә, дәрәҗәле кешеләр өчен махсус салдырылган мунчада юынып чыгу олы кунакның күңеленә хуш килгән. Табынга утыргач, куасны мактый-мактый эчкән дә әйтеп куйган: «Безнең Казан куасы куасмыни ул! Ни әйтсәң дә, Шәле куасы бүтән шул инде».

Мансур ВӘЛИЕВ.
Питрәч районы Шәле авылы

Әз-мәз мәзәк

Шәһәрдә юллар шулкадәр начар иде ки, «Без аны югалттык бугай» дигән сүзне ишеткәч, «ашыгыч ярдәм» машинасы шоферы пациентны эзләргә дип кире борылган иде.

* * *

Ял көнне бииик озак итеп йоклау – акча экономияләүнең иң яхшы ысулы!

Чәчү бетәме әле?

Авыл Сабан туе, шәһәр Сабан туе, федераль Сабантуй, татар авыллары Сабан туе, шахтерский Сабантуй, балалар Сабан туе, дини Сабантуй, дини балалар Сабан туе, театраль Сабантуй, журналистлар Сабан туе, табиблар Сабан туе, кичке Сабантуй, төнге Сабантуй – бу Сабантуйларның очы-кырые бармы? Тагын ниндиләре буласы калды әле? Чәчү бетәме әле?

Пекин метросында

Шулай бервакыт Пекин метросында бер егет белән кыз метро көтә. Егет кызга карап:

– Чу мин сянь дуф хе!

Кыз бераз уйга кала. Аннары җавап бирә:

– Янь фан си.

Егетнең ачуы чыга:

– Динь су син фа, си линь ян шо ен гу, шань ван ду зин!

Кыз битарафлык күрсәтеп:

– Жи куан гуа хе, шу ен гу шинь.

Шундый игътибар белән укыган буласыз, әйтерсең кытай телен беләсез. Ятмагыз диванда гәҗит укып, берәр файдалы эш эшләгез хет!

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 313

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+